КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 13 август г.Казань № 805

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанс тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 август, 624 нче карары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2015 ел, 11 июнь, 427 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанс тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган

микрокредит компаниясе чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 август, 624 нче карары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2015 ел, 11 июнь, 427 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 17 май, 321 нче; 2016 ел, 9 июль, 465 нче; 2016 ел, 2 сентябрь, 610 нчы; 2017 ел, 24 август, 598 нче; 2018 ел, 11 апрель, 447 нче, 2019 ел, 12 апрель, 280 нче; 2021 ел, 28 апрель, 288 нче; 2021 ел, 3 август, 676 нчы, 2021 ел, 1 декабрь, 1152 нче, 2022 ел, 28 февраль, 184 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә (алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.7 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәүне, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә тикшерүгә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүләр үткәрүгә Фондның ризалыгы, шулай ук, устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында аларның устав (җыелма) капиталларында һәм коммерция оешмалары катнашында Фонд (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләрдән тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акчалар алучы затларның аларны вәкаләтле орган тарафыннан аларга карата субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә карата ризалыгы, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә (чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр алганда);»;

2.12 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.12. Вәкаләтле орган Фондның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

2.16 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Тәртипнең 2.1 пунктындагы өченче абзацының һәм 2.3 пунктындагы дүртенче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин